**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Сәвәләй торак пунктында**
**гражданнар җыены карары**

**20.11.2025** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар һәм ялгыз өлкәннәр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (торак пунктның эчендә Яшел урамы юлларын вак таш белән сибү);
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (торак пункт эчендә юлларны вак таш белән сибү, Ленин урамы белән Яшьләр урамы киселешен бәйләү);
- урамнарны яктырту объектларын карап тору һәм аларга хезмәт күрсәтү (урамнарны яктыртуны ремонтлау);
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (2 гидрант урнаштыру);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Сабантуй үткәрелгән урында сәхнәне ремонтлау);

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы** **С.К. Маклаков**